**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 9** **13.07.2020 ел.**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрү тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Уставына таянып, Поповка авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне, әлеге карарга кушымта нигезендә редакциядә бәян итеп, расларга.
2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 21 сентябрендәге 125 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтындагы «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Поповка авыл җирлеге**
**Башлыгы урынбасары** **Т.С.Хабибуллин**